Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча 2023 елның 30 ноябрендәге гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары)

НӘТИҖӘСЕ

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча фикер алышканнан соң, гавами тыңлауларда катнашучылар тәкъдим ителгән проектның «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, РФ Җир кодексы, РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә әзерләнгәнлеген билгеләп үттеләр. Башка өстәмәләр һәм үзгәрешләр килмәде.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча чыгышларны тыңлап, гавами тыңлауларда катнашучылар карара кабул иттеләр:

1. Тәкъдим ителгән документлар нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын кабул итәргә.

2. Каралган мәсьәләне, тиешле карар кабул итү өчен, Кукмара муниципаль районы Советының чираттагы утырышының көн тәртибенә чыгарырга.

3. Гавами тыңлаулар буенча йомгакны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Рәислек итүче — [signature] — Р.Р. Хәнәфиев